| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.11.2019 Казан шәһәре № 10-11/кс

«Ореховка» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 елга юынтык су агызуга тариф билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм юынтык суны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм юынтык суны өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм юынтык суны өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Юынтык су агызуны гамәлгә ашыра торган «Ореховка» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 елга, әлеге карар кушымтасына туры китереп, юынтык су агызуга тариф билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән башлап 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Юынтык су агызуны гамәлгә ашыра торган «Ореховка» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм юынтык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.11.2019 № 10-11/кс карарына кушымта

## «Ореховка» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен юынтык су агызуга тариф

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2019 кадәр |
| | Яшел Үзән муниципаль районы | |
| 1 | «Ореховка» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Көнбатыш Ореховка, Ореховка, Дубровка һәм «Загородный клуб» коттеджлар поселогындагы кулланучылар өчен)* | 30,51 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге